**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**2016 елның «24» мартыннан** **№ 11-41**

**«Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында»**

«Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы Указының 2 статьясы нигезендә карар бирәм:

**КАРАР БИРӘ:**

1. Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар белән Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга җитәкчелек итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**